**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге**
422742, Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авылы,
Киров урамы, 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кулле-Киминское сельское поселение**
422742, Атнинский муниципальный район
с.Кулле-Кими,
ул. Кирова, 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» ноябрь 2025 г. № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы « Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 25 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә керүче Яңа Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 25 ноябре 13.00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Яңа Бәрәскә авылы, Совет урамы,29А йорты;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;

- сайлау хокукына ия булган Яңа Бәрәскә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Яңа Бәрәскә торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

2) традицион зират урыннарын ремонтлау, койма ясау, төзекләндерү (зират коймасын ремонтлау, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»

"РИЗА" "КАРШЫ"

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күлле-Киме авылы, Киров урамы 1А йорты адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Кулле-Киминского сельского поселения
Күлле-Киме авыл җирлеге советы

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гиниятов И.С.